# Чишмә башы

***Ноябрь, 2025***







Кадерле әниләребез, дәү әниләребез!

Әниләр көне уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Әни ул – иң изге, иң кадерле кеше; яшәү, наз һәм җылылык чыганагы, гаилә терәге. Бары тик әни генә, бернәрсәгә дә карамыйча, үз баласын бөтен йөрәге белән ярата, барлык кыенлыклардан саклый, шәхес итеп тәрбияли.

Кадерле әниләребез! Зирәк, акыллы һәм сабыр булуыгыз өчен сезнең алдыгызда баш иябез. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбияләүче күп балалы әниләргә һәм хатын-кызларга аерым рәхмәт сүзләрен җиткерәбез.

Сезгә саулык-сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, гаилә иминлеге телибез! Тормышыгыз тигезлектә, кадер-хөрмәттә, муллыкта узсын! Балаларыгызның игелеген күреп, шатлыкларына һәм уңышларына сөенеп озак яшәгез!



***Әниләр турында мәкальләр һәм әйтемнәр***

Ана җылысы — кояш җылысы.

Яктылык — кояш янында, яхшылык — әни янында.

Ана йөрәге — бала өчен дәрья.

Ана балага авызыннан өзеп каптыра.

Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада.

Ана ачуы — язгы кар: күп булса да тиз эри.




4 ноябрь Россиядә Халыклар бердәмлеге көне буларак билгеләп үтелә. Бу дата күпмилләтле илебез тормышында үзенең лаеклы урынын тапты, чөнки гражданлык бердәмлеге һәм халыклар арасында татулык имин киләчәк өчен нигез булып тора.




1992 нче елның 6 нчы ноябрендә, Татарстан Конституциясе катлаулы тарихи шатларда кабул ителә. Хәзерге Россия тарихында бу көн үзенчәлекле урын алып тора, чөнки бу мөһим документ республиканың күп елларга үсеш ноктасын билгеләп үтә.




Халык календарында 12 ноябрь православларның изге Зиновий Песнәген искә алу көне булып тора. Халык ырымнарына караганда, нәкъ менә шушы вакытта песнәкләр, салкыннарны тоя башлап, урманнардан кешеләрнең торакларына якынрак очып килә торган булганнар һәм кешеләрдән ярдәм көткәннәр. Борынгы әби-бабаларыбыз шунысын да билгеләгән: кошлар олаулары белән йорт янына очып килә икән, димәк, менә-менә, салкын кыш киләчәк. Аннан соң бу көнне күзәтеп баручы әби-бабаларыбыз, билгеле бер үзенчәлекләренә карап, һава торышын да әйтеп бирә торган булганнар: песнәк сызгырса – көн аяз булачак, песнәк чинаса – төнлә салкын киләчәк, җимлеккә күпләп песнәк җыелса – буран булачак һәм кар явачак. Песнәкнең рус телендәге “синица” исеме бу кошларның зәңгәр канатлы булганына карап  барлыкка килмәгән, хәтта күпләр шулай уйларга яратса да. Бу кошларның атамасы кыңгырау чыгына охшатып, яңгыратып җырлаулары аркасында  килеп чыккан.

12 ноябрь  - Песнәкләр көне. Бу көнне илнең төрле торак пунктларында яшәүчеләр “кышкы кунаклар”ны – безнең якларда кышларга калучы кошларны: песнәкләрне, купшы чыпчыкларны, карабүрекләрне, күкшәләрне, чечетларны, урман чыпчыкларын каршы алырга әзерләнә. Кешеләр алар өчен азык, шул исәптән “песнәкләр өчен тәм-томнар”: тозлы булмаган чучка мае, кыздырылмаган кабак орлыгы, көнбагыш әзерли, җимлекләр ясый һәм элеп куя.

“Бигрәк суык кышларын,
Белмим,ничек кышлармын?
Азык табу бик кыен,
Җан асрау - бар уем”,-
Яныма очып килде,
Бер песнәк шулай диде.
Ачыга икән бит песнәк,
Тик утырыйк без нишләп?!
Өйдәге бер тартмадан
Әти җимлек ясады.
Тары, көнбагыш салдык,
Песнәк тәмләп ашады.
Сыйлансын әйдә песнәк,
Арыгандыр җәй эшләп.
Күп кортларны юк итте,
Җимлектә безнең рәхәт.

13 ноябрь - көн аяз икән, иртәгәсе көннәр җилле булыр.
14 ноябрь көнне кар төшсә, язын су күп булыр. Боз катса, язга кадәр суыклар сакланыр. Бу көнне пычрак аякка иярә икән, димәк, декабрьгә кадәр суыклар булмас.
15 ноябрь көнне суык булып, әтәчләр җырласа, көннәр җылыта. Бу көнне тәрәзәдә бизәкләр хасил булса, язын яшеллек мул булыр.
16 ноябрь көнне мичтә утын шартлап янса - көчле суыкларга. Морҗадан чыккан төтен җиргә ауса, алдагы көннәрдә җылы һава торышы килер.
17 ноябрь көнне җиңелчә суык икән, кыш суык булмас.
18 ноябрьдә кар яуса, суык кыш, көзге культураларның мул уңышына ишарә.
19 ноябрь көнне кар очса, кыш карлы килер. Әгәр бу көнне өф иткән җил дә юк икән, тиздән чын суыклар килеп җитәр.
 20 ноябрь көнне ала каргалар төркемләп очса яки тавышланса, иртәгә кар явар. Бу көнне боз катса, димәк, башка җылытмый.
21 ноябрь көнне җепшек кар яуса, яз айлары яңгырлы булыр.